| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабрь 2025 ел г. Альметьевск № 3060

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 27 октябрендәге 03-12/7278 номерлы хаты нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 июнендәге 1182 номерлы, 2020 елның 16 июлендәге 959 номерлы, 2020 елның 9 декабренге 1805 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 2448 номерлы, 2023 елның 27 июнендәге 1974 номерлы, 2024 елның 21 маендагы 1847 номерлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 3685 номерлы, 2025 елның 23 маендагы 1139 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 3 пункты таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфасы | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 45 700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 43 800 |
| Бүлек җитәкчесе | 36 900 |

заказ № 4553-940

| | |
|---|---|
| Әйдәп баручы бухгалтер | 32 500 |
| Әйдәп баручы белгеч (эшчәнлек юнәлеше) | 32 500 |
| Бухгалтер | 30 600 |
| Белгеч (эшчәнлек юнәлеше) | 30 600 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдинова йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов